ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 125-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 125-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 27 ноябре
№ 461-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 17 пунктына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 74 (I өлеш), «2026 елның 31 декабренә» сүзләрен «2030 елның 31 декабренә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
# АҢЛАТМА

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) регионның турист потенциалын үстерүнең стратегик бурычларына һәм кунакханә инфраструктурасына озак сроклы инвестицияләрне җәлеп итү өчен уңайлы шартлар тудыру зарурлыгына бәйле рәвештә законнар нормаларын гамәлгә ашыру срогын озайту максатларында эшләнде.

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 17 пункты (гамәлдәге редакциядә) нигезендә 2024 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәрге чорда файдалануга тапшырылган, кимендә «өч йолдыз» категориясе булган һәм 50 номердан күбрәк номер фонды булган кунакханәләрдә вакытлыча яшәү өчен урыннар бирү буенча хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән мөлкәткә карата оешмалар өчен салым ташламалары каралган.

Әлеге үзгәрешне гамәлгә ашыру кунакханә секторында төзелеш активлыгын стимуллаштыру, номер фондын киңәйтү һәм турист хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын арттыру зарурлыгы белән аңлатыла. Срокны өстәмә арттыру инвесторларны җәлеп итүне стимуллаштыра, яңа эш урыннары булдыруга, синергетик тармакларны (транспорт, җәмәгать туклануы, хезмәт күрсәтүләр өлкәсе) үстерүгә ярдәм итә, шулай ук нәтиҗәдә кулланучылар өчен кунакханә номерларының үзкыйммәтен киметергә мөмкинлек бирә. Бу кунакханәләрнең хосусый сектор белән чагыштырганда конкурентлыкка сәләтен арттырачак, бу, үз чиратында, турист агымын легаль кунакханә секторына күчерүгә китерәчәк, салым базасын ныгытачак, хезмәт күрсәтү стандартларын арттырачак һәм кунакларның иминлеген тәэмин итәчәк.

Ташлама бирү юлы белән салым керемнәрен вакытлыча киметү инвестицияләрнең һәм уртак тармаклардан кергән салым керемнәренең күләме артуы исәбеннән, шулай ук Татарстан Республикасының туристлар җәлеп итүчәнлегенең гомуми үсешенә бәйле рәвештә капланачак.

Закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк, ә аны гамәлгә ашыру регионның икътисады һәм социаль өлкәсе өчен озак сроклы уңай нәтиҗәне тәэмин итәчәк.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, аларга үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.

Төзелеше һәм файдалануга тапшырылуы 2024 елдан гамәлгә ашырыла торган объектлар буенча бирелгән салым ташламаларының күләме елга 657,3 млн сум күләмендә бәяләнә.